**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**IV чакырылыш чираттан тыш утырыш**
КАРАРы

12 май 2023 ел № 21 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 29.10.2021 ел, № 83 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 статья - «Вәкаләтле орган карарларына, вәкаләтле орган вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү»не түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.1. «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 9 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган карарларына, вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелергә мөмкин.

6.2. Алар фикеренчә, муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре турыдан-туры бозылган контрольлек итүче затлар судка кадәр шикаять бирергә хокуклы:

1) контроль чаралар уздыру турында карарларга;

2) ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында контроль чаралар актлары, күрсәтмәләргә;

3) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затларның контроль чаралар кысаларында гамәлләренә (гамәл кылмавына).

6.3. Шикаять контрольдә торучы зат тарафыннан шикаятьне карауга вәкаләтле орган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталын һәм (яисә) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын кулланып электрон рәвештә бирелә.

Аларда дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр һәм документлар булган шикаять дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланмыйча, Россия Федерациясе дәүләт законнарын яки закон белән саклана торган башка сер турындагы законнар таләпләрен исәпкә алып, бирелә. Тиешле шикаятьне, контрольдә тотучы зат башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кабул итүендә бирә, шикаятьтә (документларда) дәүләт яки закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлар булуы турында Башкарма комитет җитәкчесенә алдан хәбәр итә.

6.4. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карала.

6.5. Вәкаләтле орган карарына шикаять, аның вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) контрольдә тотыла торган зат үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән алып 30 календарь көн эчендә бирелергә мөмкин.

Вәкаләтле орган күрсәтмәсенә шикаять контрольдә тотыла торган зат күрсәтмә алган вакыттан алып 10 эш көне эчендә бирелергә мөмкин.

Шикаять бирү срогын җитди сәбәп аркасында уздырган очракта, шикаять биргән затның үтенечнамәсе буенча әлеге срок вәкаләтле орган тарафыннан торгызылырга мөмкин.

Шикаять биргән зат шикаять буенча карар кабул ителгәнчегә кадәр аны тулысынча яки өлешчә кире алырга мөмкин. Шул ук вакытта шул ук нигезләр буенча шикаятьне кабат җибәрү рөхсәт ителми.

6.6. Вәкаләтле орган карарына, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять аны теркәгән көннән соң 20 эш көне эчендә каралырга тиеш.

Аны карау өчен башка органнар карамагында булган мәгълүматлар алу таләп ителгән очракта, шикаятьне карау срогы башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан 20 эш көненнән артык булмаган вакытка озайтылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Советы Рәисе                                                                 А.Ә.  Шәфигуллин